ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-42-05, факс:2-80-13, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«_20_»__02___2026 ел № 183

Татарстан Республикасы муниципаль районы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 11.03.2021 елгы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан бинаны торак урын, гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урын, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында»гы № 162 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 20.03.2025 № 33-ФЗ Федераль законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.01.2006 елның "Торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны авария хәлендәге һәм җимерелергә яки реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы нигезләмәне торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип раслау хакында»гы № 47 карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан бинаны торак урын, гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урын, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында» 11.03.2021 ел, № 162 карарына (алга таба - карар) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.1. Карарның 1 нче кушымтасын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 09.07.2025 елгы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма

комитетының 17.11.2023 елгы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 11.03.2021 елгы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан бинаны торак урын, гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз) торак урын, күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында бинаны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия төзү турында»гы № 162 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында"гы № 1832/1 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында"гы № 696 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

Р.М. Якупов
2-42-05

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
20.02.2026 ел № 183

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы муниципаль берәмлеге территориясендә бинаны торак урын, торак урынны гражданнар яшәү өчен яраклы (яраксыз), күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында аны бәяләү һәм тикшерү өчен ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Самонина С.П. | Ведомствоара комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Захаров А.Н. | Ведомствоара комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Андреева В.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының ведомствоара комиссиясе секретаре, инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече; |

Ведомствоара комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Долгих В.В. | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында (Бөгелмә ТО) территориаль бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Бикчәнтәева Л.З. | Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе - Әлмәт районара торак инспекциясе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Лаптева С.В. | "Татарстан Республикасы Техник инвентаризация бюросы" АҖ Әлмәт филиалының Ютазы бүлекчәсе җитәкчесе (килешү буенча); |

| | |
| --- | --- |
| Латыйпова Г.А. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге җитәкчесе; |
| Сәетгәрәева С.Р. | Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе урынбасары; |
| Миңневәлиев Р.Н. | Миңневәлиев Р.Н. «Ютазагражданпроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры (килешү буенча). |